| МИНИСТЕРСТВО<br>ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И<br>СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ<br>РЕСПУБЛИКИ<br>ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ<br>БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ<br>СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ<br>МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

04.10.2022 Казан ш № 908

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасында 14 яшьтән 18 яшькәчә балигъ булмаган гражданнарны укудан буш вакытында, эш эзләүдә кыенлыклар кичерә торган эшсез гражданнарны, урта һөнәри белеме яки югары белеме булган һәм алган белем турында һәм квалификация турында документ бирелгән датадан башлап бер ел дәвамында эш эзли торган 18 яшьтән 25 яшькәчә булган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 30 ноябрендәге 880 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасында 14 яшьтән 18 яшькәчә балигъ булмаган гражданнарны укудан буш вакытында, эш эзләүдә кыенлыклар кичерә торган эшсез гражданнарны, урта һөнәри белеме яки югары белеме булган һәм алган белем турында һәм квалификация турында документ бирелгән датадан башлап бер ел дәвамында эш эзли торган 18 яшьтән 25 яшькәчә булган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015

елның 30 ноябрендәге 880 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 10.06.2016 №337, 26.09.2018 №904, 05.03.2019 №158, 07.05.2019 №330, 14.11.2019 №1019, 29.06.2020 №468, 08.10.2020 №713, 13.10.2021 №756 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә.Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2022 елның 2022 елның 4 октябрендәге 908 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасында 14 яшьтән 18 яшькәчә балигъ булмаган гражданнарны укудан буш вакытында, эш эзләүдә кыенлыклар кичерә торган эшсез гражданнарны, урта һөнәри белеме яки югары белеме булган һәм алган белем турында һәм квалификация турында документ бирелгән датадан башлап бер ел дәвамында эш эзли торган 18 яшьтән 25 яшькәчә булган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 30 ноябрендәге 880 номерлы боерыгына кертелә торган үзгәрешләр

Преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон һәм Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «14 яшьтән 18 яшькәчә балигъ булмаган гражданнарны укудан буш вакытында, эш эзләүдә кыенлыклар кичерә торган эшсез гражданнарны, урта һөнәри белеме яки югары белеме булган һәм алган белем турында һәм квалификация турында документ бирелгән датадан башлап бер ел дәвамында эш эзли торган 18 яшьтән 25 яшькәчә булган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча эшчәнлек стандартын раслау турында» 2022 елның 28 гыйнварындагы 25н номерлы боерыгы нигезендә боерык бирәм:»;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасында 14 яшьтән 18 яшькәчә балигъ булмаган гражданнарны укудан буш вакытында, эш эзләүдә кыенлыклар кичерә торган эшсез гражданнарны, урта һөнәри белеме яки югары белеме булган һәм алган белем турында һәм квалификация турында документ бирелгән датадан башлап бер ел дәвамында эш эзли торган 18 яшьтән 25 яшькәчә булган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

1 бүлектә:

1.2 пунктта «- халыкның мәшгульлек үзәкләре (алга таба – ХМҮ)» сүзләрен «(алга таба – халыкның мәшгульлек үзәге)» сүзләренә алмаштырырга;

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Мөрәҗәгать итүчеләр булып түбәндәгеләр тора:

1) 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнар укудан буш вакытта (алга таба – балигъ булмаган гражданнар);

2) эш эзләүдә кыенлыклар кичергән һәм билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнар (алга таба – эшсез гражданнар):

инвалидлар; ирektән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәтүче учреждениеләрдән азат ителгәннәр; пенсия алды яшендәге затлар (картлык буенча, шул исәптән вакытыннан алда билгеләнгән яшькә кадәр биш ел элек); качаклар һәм күченергә мәҗбүр булганнар; хәрби хезмәттән азат ителгәннәр һәм аларның гаилә әгъзалары; балигъ булмаган балалар, инвалид балалар тәрбияләүче ялгыз һәм күп балалы ата-аналар; Чернобыль һәм башка радиация аварияләре һәм афәтләре аркасында радиация тәэсиренә дучар булган затлар;

урта һөнәри белеме яки югары белеме булган һәм алган белем турында һәм квалификация турында документ бирелгән датадан башлап бер ел дәвамында эш эзли торган 18 яшьтән 25 яшькәчә булган гражданнар.

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә (мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган үткәрә торган анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән мөрәҗәгать итүченең тиешле билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү) профильне яңасына үзгәртү үткәрелми.»;

1.5, 1.7- 1.9 пунктларын үз көчен югалткан дип танырга;

2 һәм 3 бүлекләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы

Татарстан Республикасында 14 яшьтән 18 яшькәчә балигъ булмаган гражданнарны укудан буш вакытында, эш эзләүдә кыенлыклар кичерә торган эшсез гражданнарны, урта һөнәри белеме яки югары белеме булган һәм алган белем турында һәм квалификация турында документ бирелгән датадан башлап бер ел дәвамында эш эзли торган 18 яшьтән 25 яшькәчә булган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру.

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исеме

2.2.1. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасының тиешле муниципаль берәмлекләре территориясендә халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан күрсәтелә. Халыкның мәшгульлек үзәгенә карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы гамәлгә ашыра.

2.2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба - КФҮ) аша бирергә мөмкин.

КФҮ белгече дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул итми.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

вакытлыча эш вариантларын (исемлек) тәкъдим итү;

эш бирүче Бердәм цифрлы платформада теркәлмәгән очракта, вакытлыча эшкә урнаштыру турында сөйләшүләр үткәрү турында хәбәр итү һәм гражданинга вакытлыча эшкә урнашуга юллама бирү.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә халыкны эш белән тәэмин итү һәм хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә «Работа в России» бердәм цифрлы платформасын (https://www.trudvsem.ru/) (алга таба – Бердәм цифрлы платформа), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталын (http://www.uslugi.tatarstan.ru) (алга таба – Татарстан Республикасы порталы) кулланып, электрон документ формасында бирелә (җибәрелә).

2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты

2.4.1. Мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән килгән очракта, Регламентның 3.1 пунктында (4, 5, 8, 9 пунктчаларыннан тыш) каралган административ процедуралар (гамәлләр), и-л пунктчаларыннан тыш, аның теләге буенча ул мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте дистанцион формада күрсәтелгән очракта, гариза халыкның мәшгульлек үзәгенә Бердәм цифрлы платформадан, Татарстан Республикасы порталыннан файдаланып, электрон документ рәвешендә бирелә.

Гариза мөрәҗәгать итүче тарафыннан җибәрелгән көнне халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан кабул ителгән дип санала.

2.4.2. Эш бирүченең вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру турындагы гаризасы халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан аны Бердәм цифрлы платформада теркәгән көннән соң җиде эш көне эчендә карала.

Кабул ителгән карар турында эш бирүчегә халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан белдерү гаризаны теркәгәннән слң эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көнлек срокта җиткерелә.

2.4.3. Халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан эш бирүче белән шартнамәнең төп нигезләмәләрен килештерү эш бирүче белән шартнамә төзү турында карар кабул ителгән көннән соң җиде эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Халыкның мәшгульлек үзәге белән эш бирүче арасында шартнамә эш бирүче белән вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру турында шартнамә төзү турында карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көнлек срокта гамәлгә ашырыла.

2.4.4. Халыкның мәшгульлек үзәгенә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмадан алынган төркемле гариза нигезендә балигълык яшенә җитмәгән гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру төркемле гариза халыкның мәшгульлек үзәгенә алынган көннән соңгы 30 календарь көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында (https://www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында урнаштырылган:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр;

дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт яки муниципаль хезмәткәрләрнең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

2.6.1. Эшсез гражданнар исәбендәге мөрәҗәгать итүчеләргә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар түбәндәгеләрне үз эченә ала:

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2022 елның 28 гыйнварындагы 25н номерлы боерыгы белән расланган 14 яшьтән 18 яшькәчә балигъ булмаган гражданнарны укудан буш вакытында, эш эзләүдә кыенлыклар кичерә торган эшсез гражданнарны, урта һөнәри белеме яки югары белеме булган һәм алган белем турында һәм квалификация турында документ бирелгән датадан башлап бер ел дәвамында эш эзли торган 18 яшьтән 25 яшькәчә булган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча эшчәнлек стандартына (алга таба – Стандарт) 1 нче кушымтада китерелгән, киңәш ителә торган үрнәк буенча урта һөнәри белеме яки югары белеме булган һәм алган белем турында һәм квалификация турында документ бирелгән датадан башлап бер ел дәвамында эш эзли торган 18 яшьтән 25 яшькәчә булган, эш эзләүдә кыенлыклар кичерш торган эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза;

эшсез гражданин тарафыннан тәкъдим ителгән яки халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан, шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын кулланып, ведомствоара гариза нигезендә алынган Бердәм цифрлы платформада эшсез гражданин турында белешмәләр.

2.6.2. Балигълык яшенә җитмәгән гражданнар исәбендәге мөрәҗәгать итүчеләргә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар түбәндәгеләрне үз эченә ала:

Стандартның 2 нче кушымтасында китерелгән, киңәш ителә торган үрнәк буенча 14 яшьтән алып 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза;

Стандартка карата 3 нче кушымтада китерелгән, киңәш ителә торган үрнәк буенча 14 яшьтән алып 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать итүче эшсез гражданиннан резюме.

Балигъ булмаган гражданинның гаризасы белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмадан төркемле гариза нигезендә бирелергә мөмкин (төркемле гариза идентификаторы турында мәгълүматны үз эченә ала).

Төркемле гариза эш бирүче тарафыннан халыкның мәшгульлек үзәгенә Стандартка карата 4 нче кушымтада китерелгән, киңәш ителә торган үрнәк буенча, шул исәптән Бердәм цифрлы платформаны кулланып, тапшырыла.

2.6.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында электрон рәвештәге гариза мөрәҗәгать итүче тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә гади электрон имза куллану турында» 2013 елның 25 гыйнварындагы 33 номерлы карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә гади электрон имза куллану кагыйдәләре нигезендә алынган гади электрон имза белән яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән яки көчәйтелгән квалификацияле булмаган, тикшерү сертификаты Россия Федерациясе Хөкүмәте билгели торган электрон рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада булдырылган һәм кулланыла торган имза белән имзалана.

2.6.4. Гариза мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон рәвештә түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

Бердәм цифрлы платформадагы шәхси кабинет аша;

Татарстан Республикасы порталы аша;

КФҮ аша, халыкның мәшгульлек үзәгенә, Бердәм цифрлы платформадан файдалану мөмкинлеген тәэмин итеп, шәхсән килгән очракта.

2.6.5. Мөрәҗәгать итүче электрон формада гариза биргәндә булышлык күрсәтүне сорап, халыкның мәшгульлек үзәгенә яисә КФҮ мөрәҗәгать итә ала.

Халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать иткән мөрәҗәгать итүчеләргә Бердәм цифрлы платформага, Татарстан Республикасы порталына керү мөмкинлеге бирелә, шулай ук кирәкле консультация ярдәме күрсәтелә.

Халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать иткән затта «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада бердәм идентификация һәм аутентификация системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында исәпкә алу язуы булмаса, халыкның мәшгульлек үзәге яки КФҮ, халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать итүче зат риза булган очракта, әлеге системада мөрәҗәгать итүченең процедуралар узып бетерүен тәэмин итә.

Халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән барган очракта, мөрәҗәгать итүче паспортын яисә аны алыштыра торган документны күрсәтә.

2.6.6. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында бирелә торган документлар һәм белешмәләр исемлеге:

инвалидлык турында белешмәләр (инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасыннан өземтә (гражданин тарафыннан гаризада тиешле мәгълүмат күрсәтелгән очракта) – Россия Федерациясе Пенсия фонды («Инвалидларның федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасы);

Мөрәҗәгать итүче тиешле документларны үз инициативасы буенча да тапшырырга хокуклы.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.7.1. Халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан эшсез гражданинның гаризасын кабул итүдән баш тарту нигезләре каралмаган.

2.7.2. Халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан балигълык яшенә җитмәгән гражданиннан документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре:

резюменың мәгълүматка карата таләпләргә туры килмәве;

белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешманың төркемле гариза буенча бирелгән гаризаларның рөхсәт ителгән максималь санын арттыру.

2.7.3. Гариза кабул итүдән баш тарту турында белдерү, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать иткән балигъ булмаган гражданинга резюмега бәяләү уздыру көненнән соң килә торган эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.

2.7.4. Оешманың төркемле гаризасы буенча бирелгән гаризаны кабул итүдән баш тарту турындагы белдерү балигъ булмаган гражданинга гариза кабул ителгән көнне җибәрелә.

Әлеге белдерүдә Стандартта каралган индивидуаль тәртиптә дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза җибәрү мөмкинлеге турында мәгълүмат була.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре каралмаган.

2.8.2. Россия Федерациясе гражданины паспортын яки аны алмаштыра торган документның, чит ил гражданинының шәхесен һәм гражданлыгын таныклый торган документларның, гражданлыгы булмаган затның шәхесен таныклый торган документларның булмавы яки аларны күрсәтүдән баш тартуы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

2.8.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге очракларда туктатыла:

вакытлыча эшкә урнаштыру вариантлары исемлеген алган көннән соң киләсе ике календарь көн эчендә гражданин тарафыннан Бердәм цифрлы платформа аша халыкның мәшгульлек үзәгенә вакытлыча эшкә урнаштыру вариантларыннан сайланган исемлекнең җибәрелмәве;

вакытлыча эшкә урнаштыруның сайланган варианты буенча эш бирүче белән сөйләшүләр уздыру көне һәм нәтиҗәләре турында мәгълүматны гражданин тарафыннан вакытлыча эшкә урнашуга юллама алынган көннән соңгы өч эш көне эчендә Бердәм цифрлы платформа аша халыкның мәшгульлек үзәгенә җибәрелмәве һәм (яки), эш бирүче Бердәм цифрлы платформада теркәлмәгән булса, гражданинның килү көне турында эш бирүче тамгасы һәм вакытлыча эшкә урнаштырудан баш тарту сәбәбе белән юлламаның җибәрелмәве;

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законының (алга таба – Халыкны эш белән тәэмин итү турында закон) 35 статьясындагы 2 пункты нигезендә эшсез гражданнарның теркәү исәбеннән төшерелүе;

балигълык яшенә җитмәгән гражданинны вакытлыча эшкә урнаштыруның гаризада күрсәтелгән чоры бетү яисә аңа 18 яшь тулу, әгәр әлеге вакытка кадәр халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан аның өчен вакытлыча эшкә урнаштыру вариантлары сайланмаган булса.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты

2.10.1. Мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза Бердәм цифрлы платформаны кулланып, чират тәртибендә бирелә.

Чиратта тору вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

2.10.2. Вакыты һәм датасы алдан килештерелгән очракта, мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә Бердәм цифрлы платформаны кулланып, дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гариза тапшыруны көтү вакыты биш минуттан артмаска тиеш.

Мөрәҗәгать итүчеләр өчен чират билгеләнмәгән.

2.11. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры

2.11.1. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мөрәҗәгате гариза һәм документлар алынган көнне теркәлә.

2.11.2. Гариза һәм документлар халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать иткән мөрәҗәгать итүче тарафыннан ял көне яки эшләми торган бәйрәм көнендә җибәрелгән очракта, гариза җибәрү көне дип аның артыннан киләсе эш көне санала.

Гаризаны кабул итү турында белдерү халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать иткән затка аны кабул иткән көнне җибәрелә.

2.12. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

2.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән

инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) Регламентның 2.1, 2.3, 2.4, 2.6, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларында каралган мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формалары урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

2.12.3. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объекттан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү.

2.12.4. Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәтеннән файдалану алу мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

к) халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан инвалидларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә дәүләт хезмәтеннән файдалануга комачау итә торган каршылыкларны үтүдә кирәкле башка ярдәм күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар күчермәләренең, шулай ук регистратурада аудиоконтур булуы.

2.12.5. 2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре

2.13.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре:

Үзәк бүлекчәсе бүлмәләренең җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге булган зонада урнашуы;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;

халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан инвалидларга биналарның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү;

мөрәҗәгать итүчегә индивидуаль яки ачык (телдән яки язма) мәгълүмат бирү (шәхсән кабул иткәндә, телефон элемтәсе, электрон почта чараларын кулланып, массакүләм мәгълүмат чараларында мәкаләләр, мәгълүмат материаллары (брошюралар, белешмәләр, буклетлар һ.б.) бастыру, Бердәм цифрлы платформада, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы порталында мәгълүмат урнаштыру тәртибе һәм сроклары турында, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү үрнәкләре турындамәгълүмат бирү; мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәк булган гариза формаларын һәм башка документларны файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү, шул исәптән аларны күчереп алу һәм электрон рәвештә тутыру мөмкинлеген дә биреп;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;

гариза биргәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтү вакытының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе, шул исәптән телефон элемтәсе, электрон почта, Бердәм цифрлы платформа, Бердәм портал һәм Татарстан Республикасы порталы, күпфункцияле үзәк аша, шулай ук Министрлыкның рәсми сайтында мәгълүмат алу мөмкинлеге.

2.13.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү турында Россия Федерациясе законнарындагы мәҗбүри таләпләрнең, дәүләт хезмәте күрсәткәндә Регламент нигезләмәләренең үтәлеше;

дәүләт хезмәте күрсәтү чорларының үтәлүе;

Регламентта билгеләнгән административ процедураларның эзлеклелеге саклану;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуның нигезлелеге;

дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләсе буенча нигезләнгән шикаятьләрнең булмавы.

2.13.3. Мөрәҗәгать итүченең халыкның мәшгульлек үзәге белгечләре белән үзара элемтәгә керү саны:

дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану өчен кирәкле документлар турыдан-туры тапшырылганда – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

документларны почта аша җибәргәндә, шул исәптән электрон документ формасында – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

2.13.4. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең халыкның мәшгульлек үзәге белгече белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү вакыты 15 минуттан артмый.

2.13.5. Күпфункцияле үзәктә, ерактагы эш урынында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.13.6. Мөрәҗәгать итүче КФҮ мөрәҗәгать иткән очракта, гариза халыкның мәшгульлек үзәгенә теркәлгән көннән соң икенче эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырыла.

2.13.7. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мәшгульлек үзәге белән күпфункцияле үзәк арасындагы үзара хезмәттәшлек итү тәртибе – мәшгульлек үзәге белән күпфункцияле үзәк арасында төзелә торган хезмәттәшлек турындагы килешү белән, ә күпфункцияле үзәкнең мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү тәртибе күпфункцияле үзәкнең эш регламентында җайга салына.

2.13.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм цифрлы платформадагы шәхси кабинеты аша, Татарстан Республикасы порталында, КФҮ, КФҮнең ерактагы урынында алынырга мөмкин.

2.13.9. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән: күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган; Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында

2.14.1. Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучы затлар – физик затлар регистрында үзләре турында белешмәләр булган гражданнарга, өч эш көне эчендә халыкның мәшгульлек үзәгенә килеп китүне тәкъдим итеп, җәмәгать эшләрендә катнашу өчен буш эш урыны (вакантлы вазыйфа)

булуы турында белешмәләрне эшкә алучы заттан алу турында телефон элемтәсе яки электрон элемтә ярдәмендә мәгълүмат алу мөмкинлеге тудырыла.

2.14.2. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә кулланыла:

Бердәм цифрлы платформа;

Физик затлар реестры.

2.14.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары.

3.1. Дәүләт хезмәте түбәндәге административ процедураларны (гамәлләрне) үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә;

2) эш бирүченең гаризасын кабул итү;

3) мәгълүматлар алу, ведомствоара гаризалар төзү һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру;

5) белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмадан халыкның мәшгульлек үзәгенә төркемле гариза нигезендә балигъ булмаган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру;

6) гражданнарны вакытлыча эшкә урнашуга юллау;

7) төркемле гариза нигезендә гариза биргән балигъ булмаган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруга юллау;

8) вакытлыча эшкә урнашу чорында гражданнарга матди ярдәм билгеләү һәм түләү;

9) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү;

10) техник хатаны (язу хатасын, басма хатаны, грамматик яки арифметик хатаны яки шуңа охшаш хатаны) төзәтү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә

3.2.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән, телефон, почта, электрон почта аша, техник мөмкинлек булганда, шул исәптән Бердәм цифрлы платформа, Татарстан Республикасы порталы аша һәм (яки) халыкның мәшгульлек үзәгенә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итә.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече шәхсән, телефон, почта, электрон почта һәм (яки) Бердәм цифрлы платформа, Татарстан Республикасы порталы аша, мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгать итү ысулына карап, мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча да, консультацияләр бирә.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Процедураның максималь вакыты: процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

3.3. Гражданинның гаризасын кабул итү

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче Бердәм цифрлы платформа аша гариза белән мөрәҗәгать иткәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү буенча гамәлләр.

Гариза һәм аңа беркетелгән документлар Бердәм цифрлы платформа аша халыкның мәшгульлек үзәгенә алына.

3.3.2. Мөрәҗәгать итүче тапшырган документларны кабул итү һәм Россия Федерациясе законнарында, шул исәптән әлеге Регламентта билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәве буенча беренчел тикшерү уздыруның максималь чоры – бер эш көне, гамәлнең озынлыгы – 15 минут.

Административ процедураның (гамәлнең) нәтиҗәсе булып гаризаны кабул итү тора.

Нәтиҗә Бердәм цифрлы платформада электрон формада теркәлә.

3.4. Мәгълүматлар алу, ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр төзү һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү

3.4.1. Организмындагы функцияләре бозылган булуын һәм яшәешендәге чикләмәләрне исәпкә алып, инвалид өчен кирәкле, медик-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан киңәш ителә торган хезмәт һәм һөнәри эшчәнлек төрләрен сайлап алу өчен кирәкле хосусый тернәкләрндерү программасы белешмәләре «Инвалидларның федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече, ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасыннан һәм аңа тоташтырыла торган төбәк ведомствоара электрон хезмәттәшлек системаларыннан файдаланып, мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү турына гариза белән мөрәҗәгать иткән вакытта электрон документ формасында ведомствоара рәсми мөрәҗәгать формалаштыра.

Процедураны үтәү вакыты: гаризаны теркәгән көнне.

Процедураның нәтиҗәсе булып ведомствоара электрон рәсми мөрәҗәгать формалаштыру һәм җибәрү тора.

3.4.2. Әлеге Регламентның 3.4.1 пунктында каралган ведомствоара гаризаны әзерләү һәм җибәрү срогы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү кагыйдәләрен, шул исәптән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлекне оештыруның киңәш ителә торган кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 23 июнендәге 963 номерлы карары нигезендә ведомствоара гаризаны юллаган вакыттан башлап 48 сәгатьтән артып китмәскә тиеш.

Әлеге Регламентның 3.4.1 пунктының беренче абзацында күрсәтелгән һәм аларны әзерләү өчен өстәмә гамәлләр кылу таләп ителмәгән документлар һәм мәгълүмат мөрәҗәгать иткән вакытта ведомствоара гариза нигезендә электрон формада бирелә.

3.4.3. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазь чыганакта башкарылырга мөмкин:

1) сорала торган белешмәләр электрон формада булмауга бәйле рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне электрон формада гамәлгә ашырып булмаган очракта;

2) ведомствоара гариза җибәргәндә, кәгазь чыганакта документларның оригиналларын тапшырырга кирәк булганда.

3.5. Гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру.

3.5.1. Гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

1) гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру мөмкинлеге турында мәгълүмат җыю һәм анализлау;

2) гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру өчен эш бирүчеләргә мәгълүмат бирү, аларны сайлап алу;

3) гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру турында килештерү һәм эш бирүче белән шартнамә төзү;

4) гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру турында эш бирүчеләр белән төзелгән шартнамәләр турындагы белешмәләрне Бердәм цифрлы платформага кертү, гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру өчен вакансияләр базасын формалаштыру.

3.5.2. Гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру мөмкинлеге турында мәгълүмат җыю һәм анализлау

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече мәгълүматны җыя һәм анализлый, түбәндәгеләрне исәпкә алып:

икътисад эшчәнлеге, оешмаларның финанс-икътисад торышы төрләре буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге (алга таба – муниципаль берәмлек) территориясендә урнашкан оешмалар һәм хезмәткәрләр санының бүленешен;

кадрларның һөнәри үсеш программаларын анализлау, хезмәт ресурсларына ихтыяҗның һөнәри-квалификация структурасын фаразлау нәтиҗәләрен;

муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеш перспективаларыннан чыгып, эш бирүчеләрнең хезмәт ресурсларына булган ихтыяҗын бәяләүне;

алган белем, һөнәри-квалификация структурасы, туры килә торган эш эзләүнең дәвамлылыгы, билгеле бер категория гражданнарына бәйле рәвештә эшкә урнашуга комачаулый торган сәбәпләр, туры килә торган эш эзләүдә кыенлыклар кичерә торган гражданнарның составын;

тормыш эшчәнлеге чикләнгән гражданнар өчен инфраструктураның үтемлелеген;

вакытлыча эшкә урнашуда катнашу буенча гражданнар арасындагы ихтыяҗны;

гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру буенча эш бирүчеләр һәм җирле үзидарә органнары тәкъдимнәрен;

гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру срокларын һәм дәвамлылыгын;

гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру шартларын;

гражданинның яшәү урыныннан вакытлыча эшкә урнашу урыныннан булган ераклыкны.

3.5.3. Гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру өчен эш бирүчеләргә мәгълүмат бирү, аларны сайлап алу.

3.5.3.1. Халыкның мәшгульлек үзәге эш бирүчеләргә гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру тәртибе турында хәбәр итә.

3.5.3.2. Халыкның мәшгульлек үзәге гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру өчен эш бирүчеләрне сайлап ала, түбәндәгеләрне исәпкә алып:

булдырыла торган эш урыннары санын һәм үзләре өчен вакытлыча эшкә урнаштыру оештырыла торган гражданнар санын;

эш бирүченең индивидуаль тернәкләндерү яки абилитация программасын исәпкә алып, инвалид  өчен эш урыны һәм хезмәт шартлары булуын яки булдыру мөмкинлеген;

гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру урынына транспорт үтемлелеген;

гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру шартларын;

гражданинның категориясенә карап, вакытлыча эшкә урнаштыру срокларын һәм дәвамлылыгын;

эш бирүче тарафыннан Россия Федерациясе хезмәт законнарын һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның үтәлүен;

вакытлыча эшкә урнашу чоры тәмамланганнан соң гражданнарны даими эш урынына урнаштыру мөмкинлеген бәяләүне;

эш бирүченең гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны финанслау өчен акчалары булуын.

Үзенә карата килешү төзү турында карар кабул ителә торган эш бирүчене билгеләү критерийлары:

шундый ук һөнәрләр (белгечлекләр) буенча яисә шундый ук эшне башкарганда башка эш  бирүчеләр белән чагыштырганда хезмәт өчен югарырак түләү дәрәҗәсен тәкъдим итүе;

шундый ук һөнәрләр (белгечлекләр) буенча яисә шундый ук эшне башкарганда тәкъдим ителә торган эш хакының күләме бер үк суммада булган очракта, гаризаның халыкның мәшгульлек үзәгенә башка эш бирүчеләргә караганда алданрак тапшырылган булуы (гаризаны халыкның мәшгульлек үзәгендә теркәү датасы буенча).

Процедураны үтәү вакыты: гариза аны Бердәм цифрлы платформада теркәлгәннән соң җиде эш көне эчендә карала. Кабул ителгән карар турында эш бирүчегә белдерү гаризаны теркәгәннән слң эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көнлек срокта җиткерелә.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза карау нәтиҗәләре буенча эш бирүче белән килешү төзү яки төзүдән баш тарту турында карар кабул итү һәм эш бирүчегә кабул ителгән карар турында хәбәр җибәрү.

3.5.4. Гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру турында килештерү һәм эш бирүче белән шартнамә төзү

3.5.4.1. Халыкның мәшгульлек үзәге белгече шартнамә проектын әзерләгәндә эш бирүче белән түбәндәгеләрне килештерә:

гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру тәртибе һәм шартларын;

даими эш урыннарын биләү өчен эшчеләр арасыннан сайлап алуны күздә тота торган нигезләмәләрне;

гражданнарның вакытлыча эшкә урнаштыруда катнашуын раслаучы белешмәләр бирү тәртибе һәм срокларын;

халыкның мәшгульлек үзәгенең һәм оешманың хокукларын, бурычларын һәм җаваплылыгын;

шартнамәнең гамәлдә булу срокларын;

шартнамәне туктату тәртибен һәм шартларын.

Процедураны үтәү вакыты: процедура эш бирүче белән шартнамә төзү турында карар кабул ителгәннән соң җиде эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: шартнамә проектын билгеләнгән тәртиптә килештерү һәм раслау өчен халыкның мәшгульлек үзәге директорына тапшыру.

3.5.4.2. Шартанмә төзү.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече билгеләнгән тәртиптә ике нөсхәдә шартнамә рәсмиләштерүне гамәлгә ашыра.

Процедураны үтәү вакыты: процедура эш бирүче белән вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру турында шартнамә төзү турында карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көнлек срокта гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: халыкның мәшгульлек үзәге белән эш бирүче арасында төзелгән шартнамә.

3.5.5. Гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру турында эш бирүчеләр белән төзелгән шартнамәләр турындагы белешмәләрне Бердәм цифрлы платформага кертү, гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру өчен вакансияләр базасын формалаштыру

Халыкның мәшгульлек үзәге гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру турында эш бирүчеләр белән төзелгән шартнамәләр турындагы белешмәләрне Бердәм цифрлы платформага кертә.

Бердәм цифрлы платформада әлеге шартнамәләрнең реестры формалаштырыла һәм алып барыла.

Процедураны үтәү вакыты: халыкның мәшгульлек итү үзәге белән эш бирүче арасында шартнамә төзелгән көнне.

Процедураның нәтиҗәсе: гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру турында эш бирүчеләр белән төзелгән шартнамәләр һәм вакытлыча эш урыннары турында Бердәм цифрлы платформадагы белешмәләр.

3.6. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмадан халыкның мәшгульлек үзәгенә төркемле гариза нигезендә балигъ булмаган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру

3.6.1. Халыкның мәшгульлек үзәгенә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмадан төркемле гариза алынган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге:

а) төркемле гаризаны Бердәм цифрлы платформада аны алганнан соң бер эш көне эчендә терки;

б) төркемле гаризада булган балигъ булмаган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру шартларын анализлый;

в) эш бирүчеләрне сайлый һәм төркемле гариза нигезендә балигъ булмаган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру тәртибе турында хәбәр итүне гамәлгә ашыра;

г) төркемле гариза нигезендә балигъ булмаган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру турында эш бирүче белән шартнамә төзи;

д) эш бирүче белән төзелгән шартнамә турындагы мәгълүматны Бердәм цифрлы платформага кертә, шуннан соң Бердәм цифрлы платформада автомат режимда төркемле гаризага идентификатор беркетелә;

е) белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешманың вәкаләтле вәкиленә төркемле гаризаның идентификаторы турында хәбәр итә, аңа балигъ булмаган гражданнар тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирү тәртибе һәм тиешле гаризада төркемле гариза идентификаторын күрсәтү кирәклеге турында мәгълүмат җиткерә.

Әлеге пунктның «б» - «е» пунктчаларында каралган административ гамәлләрне башкару срогы – халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан төркемле гариза алынган көннән соң 30 календарь көн.

Процедураның нәтиҗәсе: беркетелгән идентификаторы белән формалаштырылган төркемле гариза.

3.6.2. Төркемле гариза нигезендә гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча эш бирүчеләрдән тәкъдимнәр булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге төркемле гаризаны алган көннән соңгы 30 календарь көн эчендә аны, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы тиешле оешмага нигезле баш тартуны җибәреп, кире кага.

3.7. Гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру өчен юллау түбәндәге административ процедуралардан (гамәлләрдән) тора:

а) гражданин турындагы мәгълүматларны анализлау нигезендә эшсез гражданинга вакытлыча эшкә урнашуда катнашу турында тәкъдим формалаштыру һәм җибәрү;

б) Бердәм цифрлы платформада (эш бирүчеләр белән төзелгән шартнамәләр нигезендә вакытлыча эшкә урнашу өчен вакансияләр базасында) булган ирекле эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) турында белешмәләргә карап, гражданин белән вакытлыча эшкә урнашу вариантларын сайлау һәм килештерү;

в) гражданинның вакытлыча эшкә урнашу кандидатурасын эш бирүче белән килештерү;

г) эш бирүче Бердәм цифрлы платформада теркәлмәгән очракта, вакытлыча эшкә урнаштыру турында сөйләшүләр үткәрү турында белдерүләр җибәрү һәм (яисә) гражданинга вакытлыча эшкә урнашуга юллама бирү;

д) гражданинның вакытлыча эшкә урнашу вариантыннан баш тартуын рәсмиләштерү;

е) гражданинның вакытлыча эшкә урнашуын теркәү.

3.7.1. Гражданин турындагы мәгълүматларны анализлау нигезендә эшсез гражданинга вакытлыча эшкә урнашуда катнашу турында тәкъдим формалаштыру һәм җибәрү

3.7.1.1. Халыкның мәшгульлек үзәге эшсез гражданин турында Бердәм цифрлы платформага кертелгән документлар һәм (яки) үзе тарафыннан тапшырылган яки халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан, шул исәптән электрон хезмәттәшлекнең бердәм ведомствоара системасын кулланып, ведомствоара гариза нигезендә алынган белешмәләрне анализлый.

Процедураны үтәү вакыты: процедура гариза кабул ителгән көнне (мөрәҗәгать итүчене туры килерлек эш эзләү максатларында теркәгән, эшсез мөрәҗәгать итүчене теркәгән очракта) башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүче турындагы мәгълүматларны анализлау.

3.7.1.2. Халыкның мәшгульлек үзәге, Бердәм цифрлы платформаны кулланып, эшсез гражданин турындагы белешмәләрне анализлау нәтиҗәсендә алынган белешмәләр нигезендә вакытлыча эшкә урнашуда катнашу турында тәкъдим формалаштыра һәм эшсез гражданинга җибәрә.

Тәкъдим шулай ук Бердәм цифрлы платформада автомат рәвештә дә формалашырга мөмкин.

Процедураны үтәү вакыты: процедура тәкъдим формалаштырылган көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим җибәрү.

3.7.1.3. Халыкның мәшгульлек үзәге эшсез гражданинга хәбәр итә:

Бердәм цифрлы платформа аша халыкның мәшгульлек үзәгенә вакытлыча эшкә урнашу турындагы тәкъдимне карау нәтиҗәләрен җибәрү кирәклеге турында;

тәкъдимне карау нәтиҗәсен Бердәм цифрлы платформаны кулланып, халыкның мәшгульлек үзәгенә җибәрү срогы турында.

Халыкны эш белән тәэмин итү турындагы законның 4 статьясындагы 3 пункты нигезендә вакытлыча характердагы эш урынлы булган эшсез гражданин тарафыннан тәкъдимне карау срогы тәкъдим алынганнан соң 14 календарь көн тәшкил итә. Эшсез гражданнарның башка категорияләре өчен тәкъдимне карау вакыты билгеләнми.

Процедураны үтәү вакыты: тәкъдим формалаштырылган көнне.

Процедураның нәтиҗәсе: эшсез гражданинга тәкъдимне карау нәтиҗәсен җибәрү срогы турында хәбәр итү.

3.7.1.4. Эшсез гражданин халыкның мәшгульлек үзәгенең вакытлыча эшкә урнашуда катнашу турындагы тәкъдименнән баш тарткан очракта (шул исәптән Регламентның 3.7.1.3 пунктчасының дүртенче абзацында каралган чор эчендә эшсез гражданин тарафыннан Бердәм цифрлы платформа аша әлеге тәкъдимне карау нәтиҗәләре җибәрелмәгән очракта да), халыкның мәшгульлек үзәге эшсез гражданинның вакытлыча эшкә урнашуда катнашудан баш тартуын Бердәм цифрлы платформада терки.

Процедураны үтәү вакыты: эшсез гражданин вакытлыча эшкә урнашуда катнашудан баш тарткан көнне.

Процедураның нәтиҗәсе: эшсез гражданинның баш тартуын Бердәм цифрлы платформада теркәү.

3.7.2. Бердәм цифрлы платформада (эш бирүчеләр белән төзелгән шартнамәләр нигезендә вакытлыча эшкә урнашу өчен вакансияләр базасында) булган ирекле эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) турында белешмәләргә карап, гражданин белән вакытлыча эшкә урнашу вариантларын сайлау һәм килештерү

3.7.2.1. Халыкның мәшгульлек үзәге гражданинга вакытлыча эшкә урнашу вариантларын сайлап ала, түбәндәгеләр юлы белән:

гражданин турында белешмәләрне исәпкә алып, вакытлыча эшкә урнаштыру һәм вакытлыча эшкә урнаштыру вариантларын сайлап алу вариантларының автоматик рәвештә формалаштырылган исемлеген анализлау;

Бердәм цифрлы платформа ярдәмендә вакытлыча эшкә урнашыру вариантларын өстәмә эзләү;

вакытлыча эшкә урнашу өчен 10 варианттан артык булмаган исемлек формалаштыру.

Вакытлыча эшкә урнаштыру вариантлары исемлеге автоматлаштырылган режимда, Бердәм цифрлы платформада вакансияләрне интеллектуаль эзләү технологиясен кулланып, эш бирүчеләр белән төзелгән вакытлыча эшкә урнаштыру өчен вакансияләр базасында булган ирекле эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар турында белешмәләрдән чыгып, гражданинның гаризасын кабул иткән көннән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмаган срокта формалаштырыла.

Процедураны үтәү вакыты: гражданинның гаризасын кабул иткән көннән соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча.

Процедураның нәтиҗәсе: гражданин тарафыннан вакытлыча эшкә урнашу өчен буш эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар турында мәгълүматлар тупланган исемлекне алу.

3.7.2.2. Вакытлыча эшкә урнаштыру өчен ирекле эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар турында белешмәләр Бердәм цифрлы платформада булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге гражданин өчен, вакытлыча эшкә урнаштыру өчен эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар турында белешмәләр Бердәм цифрлы платформага килгән көннән соңгы ике эш көне узганчы, вакытлыча эшкә урнашу вариантларын сайлап ала.

Процедураны үтәү вакыты: вакытлыча эшкә урнашу өчен эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар турында белешмәләр Бердәм цифрлы платформага кергән көннән соң ике эш көненнән дә соңга калмыйча.

Процедураның нәтиҗәсе: гражданин тарафыннан вакытлыча эшкә урнашу өчен буш эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар турында мәгълүматлар тупланган исемлекне алу.

3.7.2.3. Гражданин эшкә урнаштырылмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге вакытлыча эшкә урнашуның сайланган ике варианты буенча эш бирүче белән сөйләшүләр уздыру көне һәм нәтиҗәләре турында гражданиннан мәгълүмат Бердәм цифрлы платформага алынган көннән соң яисә гражданин тарафыннан гражданинның килүе турында һәм, эш бирүче Бердәм цифрлы платформада теркәлмәгән очракта, вакытлыча характердагы эшкә кабул итүдән баш тарту турында

эш бирүче тамгасы белән юллама тапшырылган көннән соң бер эш көне эчендә вакытлыча эшкә урнашу вариантларын кабат сайлый.

Процедураны үтәү вакыты: гражданиннан эш бирүче белән сөйләшүләр уздыру нәтиҗәләре турында мәгълүмат Бердәм цифрлы платформага алынганнан соң бер эш көне эчендә.

Процедура нәтиҗәсе: гражданинга вакытлыча эшкә урнашу вариантларын кабат сайлау.

3.7.2.4. Халыкның мәшгульлек үзәге, гражданин белән вакытлыча эшкә урнашу вариантларын килештерү максатларында, гражданиннан гариза кабул ителгән көннән соң яисә вакытлыча эшкә урнашу буенча сайланган ике вариант буенча эш бирүче белән сөйләшүләр уздыру көне һәм нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат Бердәм цифрлы платформага алынган көннән соң яисә, эш бирүче Бердәм цифрлы платформада теркәлмәгән булса, гражданинның килүе һәм вакытлыча характердагы эшкә кабул итүдән баш тарту сәбәбе турында эш бирүче тамгасы белән юллама гражданин тарафыннан тапшырылган көннән соң бер эш көне узганчы Бердәм цифрлы платформа аша гражданинга түбәндәгеләрне җибәрә:

а) вакытлыча эшкә урнашуның 10 артык булмаган варианты булган исемлек;

б) гражданин өчен түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алган белдерү:

тәкъдим ителгән вакытлыча эш вариантларын өстенлекле тәртиптә билгеләп, шул ук вакытта ким дигәндә ике өстенлекле вакытлыча эш вариантын сайларга кирәклеге турында;

өстенлек тәртиптә билгеләнгән вакытлыча эшкә урнашу вариантларын Бердәм цифрлы платформаны кулланып, халыкның мәшгульлек үзәгенә вакытлыча эшкә урнашу вариантларын алган көннән соңгы ике календарь көн эчендә җибәрү кирәклеге турында;

Халыкны эш белән тәэмин итү турындагы закон нигезләмәләре турында.

Процедураны үтәү вакыты: гражданинның гаризасын кабул иткән көннән соң яисә эш бирүче белән сөйләшүләр уздыру нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат гражданиннан Бердәм цифрлы платфрмага килгән көннән соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча.

Процедураның нәтиҗәсе: гражданинга вакытлыча эшкә урнашу вариантларын җибәрү.

3.7.2.5. Регламентның 3.7.3.4 пунктындагы «б» пунктчасының өченче абзацында каралган вакыт эчендә халыкның мәшгульлек үзәгенә гражданин тарафыннан вакытлыча эшкә урнаштыру вариантларының өстенлекле рәвештә билгеләнгән тәртибе җибәрелмәгән очракта, әлеге факт Бердәм цифрлы платформада теркәлә.

Процедураны үтәү вакыты: гражданин тарафыннан вакытлыча эшкә урнашуның өстенлекле тәртиптә билгеләнгән вариантларын җибәрү вакыты узганнан соң бер эш көне эчендә.

Процедураның нәтиҗәсе: гражданинның вакытлыча эшкә урнашу вариантларының өстенлекле тәртиптә билгеләнгән исемлеген җибәрмәвен Бердәм цифрлы платформада теркәү.

3.7.3. Гражданинның вакытлыча эшкә урнашу кандидатурасын эш бирүче белән килештерү

Халыкның мәшгульлек үзәге вакытлыча эшкә урнаштыру өчен гражданиннан өстенлек буенча билгеләнгән вакансияләр исемлеге алынган көннән соңгы бер эш көненнән соңга калмаган срокта эш бирүче белән вакытлыча эшкә урнаштыру турында гражданинның кандидатурасын килештерә, түбәндәге гамәлләрне башкару юлы белән:

вакытлыча эшкә урнаштыруның ике өстенлекле вариантыннан башлап, гражданин билгеләгән вакытлыча эшкә урнаштыру вариантларының актуальлеген тикшерү һәм алга таба – гражданин билгеләгән өстенлек тәртибендә;

эш бирүчеләр белән телефон элемтәсе яки электрон элемтә аша, шул исәптән «Интернет» челтәре аша эш бирүчедән ризалык алынганчыга кадәр актуаль булган, гражданин тарафыннан өстенлекле тәртиптә билгеләнгән һәр вакансия буенча вакытлыча эшкә урнаштыру турында сөйләшүләр уздыру өчен гражданин кандидатурасын килештерү;

гражданин кандидатурасын эш бирүче белән килештерү турындагы белешмәләрне Бердәм цифрлы платформага кертү.

Процедураны үтәү срогы: гражданиннан вакытлыча эшкә урнаштыру вакансияләренең өстенлекле рәвештә билгеләнгән исемлеге алынган көннән соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча.

Процедураның нәтиҗәсе: эш бирүче белән вакытлыча эшкә урнаштыру турында сөйләшүләр уздыруга гражданин кандидатурасын килештерү.

3.7.4. Эш бирүче Бердәм цифрлы платформада теркәлмәгән очракта, вакытлыча эшкә урнаштыру турында сөйләшүләр үткәрү турында белдерүләр җибәрү һәм (яисә) гражданинга вакытлыча эшкә урнашуга юллама бирү

3.7.4.1. Халыкның мәшгульлек үзәге эш бирүчеләр белән гражданинның кандидатурасын килештерү нәтиҗәләре нигезендә, гражданиннан вакытлыча эшкә урнашу өчен өстенлекле рәвештә билгеләнгән исемлек алынган көннән соң бер эш көне узганчы, Бердәм цифрлы платформаны кулланып, вакытлыча эшкә урнаштыру турында сөйләшүләр үткәрү турында гражданинга белдерү җибәрә.

Процедураны үтәү срогы: гражданиннан вакытлыча эшкә урнашу өчен вакансияләрнең өстенлекле рәвештә билгеләнгән исемлеге алынган көннән соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча.

Процедураның нәтиҗәсе: гражданинга Бердәм цифрлы платформа ярдәмендә вакытлыча эшкә урнаштыруу турында сөйләшүләр үткәрелүе турында белдерү җибәрү.

3.7.4.2. Эш бирүче Бердәм цифрлы платформада теркәлмәгән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә бәйле документларның формаларын раслау турында» 2021 елның 20 октябрендәге 738н номерлы боерыгына 17 нче кушымта нигезендә вакытлыча эшкә урнашуда катнашу өчен гражданинга юллама рәсмиләштерә.

Вакытлыча эшкә урнашуда катнашу өчен гражданинга юллама гражданинга әлеге юллама белән аннан вакансияләрнең өстенлекле нигездә билгеләнгән исемлеге алынган көннән соң килә торган бер эш көненнән соңга калмыйча җибәрелә.

Процедураны үтәү срогы: гражданиннан вакытлыча эшкә урнашу өчен вакансияләрнең өстенлекле рәвештә билгеләнгән исемлеге алынган көннән соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча.

Процедураның нәтиҗәсе: гражданинга вакытлыча эшкә урнашуда катнашу өчен кәгазьдә юллама рәсмиләштерү һәм җибәрү.

3.7.4.3. Гражданинга берьюлы иң күбе ике белдерү генә (вакытлыча эшкә урнашу өчен юллама) җибәрелә (бирелә) ала.

Процедураны үтәү вакыты: эш бирүчедән гражданин кандидатурасын хуплау турында хәбәр алынган көнне.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә белдерүләр (вакытлыча эшкә урнашуга юлламалар) җибәрү.

3.7.4.4. Халыкның мәшгульлек үзәге гражданинга хәбәр итә:

халыкның мәшгульлек үзәгеннән белдерү (вакытлыча эшкә урнашуга юллама) алынган көннән соң килә торган өч эш көне эчендә, Бердәм цифрлы платформаны кулланып, вакытлыча эшкә урнашу буенча сайланган ике вариант буенча эш бирүчеләрнең вакансияләренә җавап формалаштыру, эшкә урнашу турында сөйләшүләр уздыру көнен һәм вакытын эш бирүче белән килештерү, халыкның мәшгульлек үзәгенә вакытлыча эшкә урнашу өчен сайланган ике вариант буенча эш бирүче белән сөйләшүләр уздыру көне һәм нәтиҗәләре турында Бердәм цифрлы платформаны кулланып җибәрү һәм (яки) эш бирүче Бердәм цифрлы платформада теркәлмәгән булса, гражданинның килгән көне һәм вакытлыча характердагы эшкә алудан баш тарту сәбәбе турында эш бирүче тамгасы куелган юлламаны тапшыру кирәклеге турында;

Халыкны эш белән тәэмин итү турындагы закон нигезләмәләре турында.

Бу мәгълүмат белдерүдә була.

Процедураны үтәү вакыты: мөрәҗәгать итүчегә белдерүләр (вакытлыча эшкә урнашу өчен юлламалар) җибәрелгән көнне.

Процедураның нәтиҗәсе: гражданинга эш бирүче тамгасы белән вакытлыча эшкә урнашуда катнашу өчен бирелгән юлламаны тапшыру кирәклеге турында хәбәр итү.

3.7.4.5. Халыкның мәшгульлек үзәге эш бирүчегә гражданинны вакытлыча эшкә урнаштыру турында сөйләшүләр уздыру нәтиҗәләре турында халыкның мәшгульлек үзәгенә мәгълүмат җиткерү кирәклеге турында хәбәр итә:

а) халыкның мәшгульлек үзәгеннән җибәрелгән гражданинны эшкә кабул иткән очракта, эш бирүче биш көнлек чорда бу хакта Бердәм цифрлы платформаны кулланып, гражданинны эшкә алу көнен, хезмәт шартнамәсе турындагы белешмәләрне күрсәтеп, халыкның мәшгульлек үзәгенә хәбәр итә яисә, эш бирүче Бердәм цифрлы платформада теркәлмәгән булса, гражданинга бирелгән юлламаны халыкның мәшгульлек үзәгенә кире кайтара;

б) халыкның мәшгульлек үзәге юллаган гражданинны эшкә алудан баш тарткан очракта, эш бирүче халыкның мәшгульлек үзәгенә гражданин белән вакытлыча эшкә

урнаштыру турында сөйләшүләр уздырылган көн турында һәм вакытлыча характердагы эшкә кабул итүдән баш тарту сәбәбе турында Бердәм цифрлы платформаны кулланып хәбәр итә яисә, эш бирүче Бердәм цифрлы платформада теркәлмәгән булса, гражданин килгән көн, вакытлыча характердагы эшкә алудан баш тарту сәбәбе турында тамга ясап, юлламаны гражданинга кире кайтара.

Әлеге мәгълүмат вакытлыча эшкә урнашу турында сөйләшүләр үткәрү турындагы белдерүдә була.

Процедураны үтәү срогы: гражданин тарафыннан эш бирүче белән сөйләшүләр уздыру датасы һәм вакыты турында мәгълүмат җибәрелгән көнне.

Процедураның нәтиҗәсе: халыкның мәшгульлек үзәгенә гражданин тарафыннан вакытлыча эшкә урнашу турында уздырылган сөйләшүләрнең нәтиҗәләре турында Бердәм цифрлы платформа аша мәгълүмат җибәрү.

3.7.5. Гражданинның вакытлыча эшкә урнашу вариантыннан баш тартуын рәсмиләштерү

Гражданин вакытлыча эшкә урнашу вариантыннан баш тарткан яки вакытлыча эшкә урнашу турында сөйләшүләр уздырудан баш тарткан очракта һәм (яки) Регламентның 3.7.5.4 пунктчасында каралган срок эчендә халыкның мәшгульлек үзәгенә сайланган вакытлыча эшкә урнашу вариантлары буенча сөйләшүләр уздыру көне һәм нәтиҗәләре турында гражданин тарафыннан мәгълүмат җибәрелмәсә яки (эш бирүче Бердәм цифрлы платформада теркәлмәгән очракта) гражданинның килгән көне һәм эшкә алудан баш тарту сәбәбе турында эш бирүче тамгасы белән юлламаны тапшырмаган очракта, әлеге факт автомат рәвештә Бердәм цифрлы платформада теркәлә.

3.7.6. Гражданинның вакытлыча эшкә урнашуын теркәү

3.7.6.1. Халыкның мәшгульлек үзәге гражданинны вакытлыча эшкә урнаштыру турындагы мәгълүматларны ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын кулланып раслый.

Процедураны үтәү вакыты: эш бирүче белән әңгәмә уздыру нәтиҗәләре турында мәгълүмат алынган көнне.

Процедураның нәтиҗәсе: гражданинның вакытлыча эшкә урнашуы турындагы мәгълүматларны раслау.

3.7.6.2. Сөйләшүләрне үткәрү нәтиҗәләре буенча гражданинга вакытлыча эшкә урнаштырудан баш тартылган очракта, Регламентның 3.7.1 пунктындагы «в» - «е» пунктчаларында күрсәтелгән административ процедуралар (гамәлләр) кабат гамәлгә ашырыла.

3.8. Төркемле гариза нигезендә гариза биргән балигъ булмаган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруга юллау түбәндәге административ процедураларны (гамәлләрне) үз эченә ала:

а) төркемле гариза идентификаторы булган балигъ булмаган гражданинның гаризасын кабул итү;

б) төркемле гариза һәм эш бирүче белән төзелгән вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру турындагы шартнамә нигезендә балигъ булмаган гражданин белән вакытлыча эшкә урнашу вариантын сайлау һәм килештерү;

в) төркемле гариза нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза биргән балигъ булмаган гражданинның вакытлыча эшкә урнашу вариантыннан баш тартуын рәсмиләштерү;

г) төркемле гариза нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза биргән балигъ булмаган гражданинны вакытлыча эшкә урнаштыруны теркәү.

3.8.1. Халыкның мәшгульлек үзәгенә балигъ булмаган гражданин тарафыннан төркемле гариза идентификаторы булган гариза җибәрелгән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге:

а) Бердәм цифрлы платформаны кулланып, автомат режимда, гаризаны төркемле гаризага берләштерә, әгәр төркемле гариза буенча тапшырылган гаризаларның гомуми саны максималь рөхсәт ителгән санны арттырып җибәрмәсә, балигъ булмаган гражданиннан гаризаны кабул итә һәм гаризаны кабул иткән көнне аны кабул итү турында белдерү җибәрә;

б) төркемле гариза буенча тапшырылган гаризаларның гомуми саны максималь мөмкин булган санны арттырып җибәргән очракта, балигъ булмаган гражданинның гаризасын кире кага, балигъ булмаган гражданинга гариза юлланган көнне гаризаны кабул итүдән баш тарту турында белдерү җибәрә, аңа Регламентның 3.7.2 -3.7.7.2 пунктларында каралган тәртиптә дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирү мөмкинлеге турында хәбәр итә.

Процедураны үтәү вакыты: балигъ булмаган гражданин тарафыннан гариза юлланган көнне.

Процедураның нәтиҗәсе: гражданинның гаризасын төркемле гаризага берләштерү.

3.8.2. Балигъ булмаган гражданиннан төркемле гариза идентификаторы булган гариза кабул ителгән көннән соң бер эш көне дәвамында халыкның мәшгульлек үзәге:

а) төркемле гариза һәм эш бирүче белән төзелгән вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру турындагы шартнамә нигезендә балигъ булмаган гражданинга вакытлыча эшкә урнаштыру вариантын сайлый, балигъ булмаган гражданинга вакытлыча эшкә урнашу турында сөйләшүләр үткәрү турында белдерү җибәрә, эш бирүче белән вакытлыча хезмәт шартнамәсен рәсмиләштерү өчен кирәкле документлар һәм (яисә) белешмәләр исемлеге турында хәбәр итә;

б) эш бирүчегә һәм белем бирү эшчәнлеген алып баручы оешмага балигъ булмаган гражданинны вакытлыча эшкә урнаштыру турында сөйләшүләр уздырылуы турында белдерү җибәрә.

Процедураны үтәү вакыты: балигъ булмаган гражданиннан төркемле гариза идентификаторы булган гариза кабул ителгәннән соң бер эш көне эчендә.

Процедураның нәтиҗәсе: вакытлыча эшкә урнаштыру вариантларын сайлап алу һәм балигъ булмаган гражданинны вакытлыча эшкә урнаштыру турында сөйләшүләр уздыру турында эш бирүчегә һәм оешмага белдерүләр җибәрү.

3.8.3. Төркемле гариза нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза биргән балигъ булмаган гражданинны вакытлыча эшкә урнаштыру вариантыннан баш тартуны рәсмиләштергәндә, Регламентның 3.5.6 пунктында каралган административ процедуралар (гамәлләр) башкарыла.

3.8.4. Төркемле гариза нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза биргән балигъ булмаган гражданинны вакытлыча эшкә урнаштыруны теркәгәндә, Регламентның 3.7.7.1 пунктында каралган административ процедуралар (гамәлләр) башкарыла.

3.9. Матди ярдәм билгеләү һәм түләү

3.9.1. Халыкның мәшгульлек үзәге гражданинга вакытлыча эшкә урнашу чорында матди ярдәм күрсәтү турында карар кабул итә һәм кабул ителгән карар турында гражданинга хәбәр итә.

Процедураны үтәү вакыты: процедура ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын кулланып, гражданинны вакытлыча эшкә урнаштыру турындагы белешмәләрне раслаганнан соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә вакытлыча эшкә урнашу чорында матди ярдәм күрсәтү турында карар кабул итү һәм кабул ителгән карар турында гражданинга хәбәр итү.

3.9.2. Халыкның мәшгульлек үзәге белгече:

матди ярдәм күрсәтү чоры озынлыгын күрсәтеп, Стандартка 5 нче кушымтада китерелгән, киңәш ителә торган үрнәк буенча вакытлыча эшкә урнашу чорында матди ярдәм күрсәтү турында боерык проектын рәсмиләштерә;

мөрәҗәгать итүчегә вакытлыча эшкә урнашу чорында күрсәтелә торган матди ярдәмнең айлык күләме, аны исәпләү тәртибе һәм түләү шартлары турында мәгълүмат җиткерә;

гражданинга вакытлыча эшкә урнашу чорында матди ярдәм күрсәтү турындагы боерык проектын раслау өчен халыкның мәшгульлек үзәге директорына тапшыра.

Процедураны үтәү вакыты: мөрәҗәгать итүчегә матди ярдәм күрсәтү турында карар кабул ителгән көнне.

Процедураның нәтиҗәсе: вакытлыча эшкә урнашу чорында гражданинга матди ярдәм күрсәтү турында боерыкны рәсмиләштерү һәм гражданинга матди ярдәмне исәпләү тәртибе һәм түләү шартлары турында мәгълүмат җиткерү.

3.9.3. Халыкның мәшгульлек үзәге ай саен, гражданинны вакытлыча эшкә урнаштыруның бөтен чоры дәвамында эш бирүче тарафыннан бирелгән, гражданинны вакытлыча эшкә урнаштыруны раслый торган белешмәләрне, гражданин тарафыннан фактта эшләнгән вакытны (әлеге белешмәләр эш бирүче тарафыннан халыкның мәшгульлек үзәгенә Бердәм цифрлы платформа аша бирелмәгән очракта) Бердәм цифрлы платформага кертә, халыкның мәшгульлек үзәге, Бердәм цифрлы платформаны кулланып, вакытлыча эшкә урнашу чорына гражданинга матди ярдәм билгели, аны исәпләп чыгара һәм гражданинга күчерә.

Үтәү вакыты: эш бирүчедән белешмәләр алынган көннән бер эш көне эчендә.

Процедураны үтәү вакыты: эш бирүче тарафыннан бирелгән белешмәләрне Бердәм цифрлы платформага кертү.

3.9.4. Гражданинны вакытлыча эшкә алу вакытыннан алда туктатылган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге аңа матди ярдәм түләүне туктату турында карар кабул итә.

Халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан әлеге карар Стандартка 6 нчы кушымтада китерелгән, киңәш ителә торган үрнәк буенча матди ярдәм түләүне туктату турында боерык рәвешендә рәсмиләштерелә.

Халыкның мәшгульлек үзәге гражданинга, боерык чыгарылган көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча, матди ярдәм түләүне туктату турында хәбәр җибәрә.

Процедураны үтәү вакыты: вакытлыча эшкә алуны туктату турында мәгълүмат алынган көннән соң бер эш көне эчендә.

Процедураның нәтиҗәсе: матди ярдәм түләүне туктату турында боерык рәсмиләштерү һәм матди ярдәм түләүне туктату турында хәбәр җибәрү.

3.10. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече:

мөрәҗәгать итүчегә вакытлыча эшкә урнашу вариантларының (исемлеген) тәкъдим итә һәм вакытлыча эшкә урнашу турында сөйләшүләр үткәрү турында хәбәр итә;

эш бирүче Бердәм цифрлы платформада теркәлмәгән булса, гражданинга вакытлыча эшкә урнашуга юллама бирә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турындагы белдерү Бердәм цифрлы платформада, Татарстан Республикасы порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына җибәрелә.

Процедураны үтәү вакыты: тәкъдим формалаштырылган һәм сөйләшүләр уздыру көнен һәм вакытын эш бирүче белән килештергән көнне.

Процедураның нәтиҗәсе: гражданинга җибәрелгән белдерү.

3.11. Техник хатаны (язу хатасын, басма хатаны, грамматик яки арифметик хатаны яки шуңа охшаш хатаны) төзәтү

Техник хатаны төзәтү гариза бирүче тарафыннан, гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы булган документны (андый документ бирелгән булса) теркәп, Регламентның 2 нче кушымтасына ярашлы форма буенча гариза бирелгәндә гамәлгә ашырыла.

3.11.1. Халыкның мәшгульлек үзәге белгече:

- техник хата төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында терки (Регламентның 3 нче кушымтасы);

- вакытлыча эшкә урнашуга юлламаны яңадан рәсмиләштерә;

- гаризада күрсәтелгән ысул белән мөрәҗәгать итүчегә вакытлыча эшкә урнашуга юлламаны яңадан рәсмиләштерү турында хәбәр итә.

Процедураны үтәү вакыты: мөрәҗәгать итүче тарафыннан техник хатаны төзәтү турында гариза бирелгән көнне.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән, теркәлгән гариза, вакытлыча эшкә урнашу өчен яңадан рәсмиләштерелгән юллама.»;

4 бүлектә:

бүлек исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Административ регламентның үтәлешен контрольдә тоту формалары»;

4.1 пунктта «ХМҮ» сүзләрен «халыкның мәшгульлек үзәге» сүзләренә алмаштырырга;

4.2 пунктта «Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2010 елның 8 ноябрендәге 972 номерлы боерыгы белән расланган Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар (физик затлар һәм эш бирүчеләр) регистрын алып бару тәртибенең» сүзләрен «Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2021 елның 6 декабрендәге 871н номерлы боерыгы белән расланган Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затларның регистрларын алып бару тәртибен, шул исәптән аларга белешмәләр кертү тәртибен, чорларын һәм белешмәләр рәвешен, шулай ук халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрларында булган мәгълүмат төрләре исемлегенең» сүзләренә алмаштырырга;

4.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Белешмә телефоннар, дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр Регламентның (белешмәлек) кушымтасында китерелгән.»;

4.4 пунктта «ХМҮ» сүзләрен «халыкның мәшгульлек үзәге» сүзләренә алмаштырырга;

5 бүлектә:

бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның, КФҮ, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»;

5.1 пунктта «ХМҮ» сүзләрен «халыкның мәшгульлек үзәге» сүзләренә алмаштырырга;

5.2 пунктының икенче абзацында «дәүләт хезмәте» сүзләреннән соң «210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында күрсәтелгән» сүзләрен өстәргә.

5.7 пунктта «ХМҮ» сүзләрен «халыкның мәшгульлек үзәге» сүзләренә алмаштырырга;

Регламентка 1 нче, 4-6 нчы кушымталарны көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле кушымта (белешмәлек) өстәргә:

«Татарстан Республикасында 14 яшьтән
18 яшькәчә балигъ булмаган
гражданнарны укудан буш вакытында,
эш эзләүдә кыенлыклар кичерә торган
эшсез гражданнарны, урта һөнәри
белеме яки югары белеме булган һәм
алган белем турында һәм квалификация
турында документ бирелгән датадан
башлап бер ел дәвамында эш эзли торган
18 яшьтән 25 яшькәчә булган
гражданнарны вакытлыча эшкә

урнаштыруны оештыру буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең административ
регламентына (белешмәлек) кушымта

# ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЕ КҮРСӘТҮНЕ КОНТРОЛЬДӘ ТОТУНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ ОРГАННАР (УЧРЕЖДЕНИЕЛӘР) ҺӘМ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАР ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘЛӘР

1. Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре

| Халыкның мәшгульлек үзәгенең аталышы | Вазыйфа | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|---|
| «Азнакай шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85592) 7-57-90 | Czn.Aznakaevo@tatar.ru |
| «Аксубай районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84344) 2-73-94 | Czn.Aksubaevo@tatar.ru |
| «Актаныш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85552) 3-09-83 | Czn.Aktanysh@tatar.ru |
| «Алексеевск районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84341) 2-54-00 | Czn.Alekseevskoe@tatar.ru |
| «Әлки районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84346) 2-15-89 | Czn.Alkeevo@tatar.ru |
| «Әлмәт шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (8553) 32-34-99 | Czn.Almet@tatar.ru |
| «Апас районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84376) 2-12-15 | Czn.Apastovo@tatar.ru |
| «Арча районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84366) 3-17-33 | Centr.Arskiy@tatar.ru |
| «Әтнә районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84369) 2-16-51 | Czn.Atnya@tatar.ru |
| «Баулы шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85569) 5-62-29 | Czn.Bavly@tatar.ru |

| | | | |
|---|---|---|---|
| «Балтач районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84368) 2-44-19 | Czn.Baltasi@tatar.ru |
| «Бөгелмә шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85594) 4-17-60 | Czn.Bugulma@tatar.ru |
| «Буа шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84374) 3-13-73 | Czn.Buinsk@tatar.ru |
| «Югары Ослан районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84379) 2-18-99 | Czn.V-uslon@tatar.ru |
| «Биектау районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84365) 3-16-17 | CZN.VGora@tatar.ru |
| «Чүпрәле районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84375) 2-25-87 | Czn.Drozhzhanoe@tatar.ru |
| «Алабуга шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85557) 7-58-58 | Czn.Elabugi@tatar.ru |
| «Зәй шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85558) 7-15-43 | Czn.Zainsk@tatar.ru |
| «Зеленодольск шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84371) 5-64-90 | Czn.Zdol@tatar.ru |
| «Кайбыч районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84370) 2-12-60 | Czn.Kaibicy@tatar.ru |
| «Кукмара районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84364) 2-67-54 | Czn.Kukmor@tatar.ru |
| «Лаеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84378) 2-48-12 | Laish.Czn@tatar.ru |
| «Лениногорск шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85595) 5-59-70 | Czn.Leninogorsk@tatar.ru |
| «Мамадыш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85563) 3-35-57 | Czn.Mamadysh@tatar.ru |
| «Менделеевск районы халыкның мәшгульлек үзәге» | директор | (85549) 2-23-57, | Czn.Men@tatar.ru Centr.Agryzskiy@tatar.ru |

| | | | |
|---|---|---|---|
| дәүләт казна учреждениесе һәм «Менделеевск районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Әгерҗе районы филиалы | | (85551) 2-31-73 | |
| «Минзәлә районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85555) 3-23-80 | Czn.Menzelinsk@tatar.ru |
| «Мөслим районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85556) 2-55-80 | Czn.Muslymovo@tatar.ru |
| «Яр Чаллы шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм «Яр Чаллы шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Тукай районы филиалы | директор | (8552) 52-42-68 (8552) 52-96-97 | Chelny.CZN@tatar.ru Czn.Tukaev@tatar.ru |
| «Түбән Кама шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм «Түбән Кама шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Кама Аланы бүлеге | директор | (8555) 42-40-79 (8555) 33-98-61 | Czn.Nk@tatar.ru Czn.Nk@tatar.ru |
| «Яңа Чишмә районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84348) 2-30-42 | Czn.Novoshesh@tatar.ru |
| «Нурлат ш. халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84345) 2-46-30 | Czn.Nurlat@tatar.ru |
| «Питрәч районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84367) 3-04-84 | CentrZan.Pestr@tatar.ru |
| «Балык Бистәсе районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84361) 2-21-81 | Czn.R.sloboda@tatar.ru |
| «Саба районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84362) 2-28-15 | SZN.Saby@tatar.ru |
| «Сарман районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85559) 2-42-62 | Czn.Sarmanovo@tatar.ru |

| | | | |
|---|---|---|---|
| «Спас районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84347) 3-07-72 | Czn.Bolgar@tatar.ru |
| «Тәтеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм «Тәтеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Кама Тамагы районы филиалы | директор | (84373) 2-63-29, (84377) 2-14-67 | Czn.Tetyushi@tatar.ru Filial.K-uste@tatar.ru |
| «Теләче районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84360) 2-13-51 | Czn.Tyulyachi@tatar.ru |
| «Чирмешән районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84396) 2-54-59 | Czn.Cheremshan@tatar.ru |
| «Чистай шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84342) 5-13-34 | Czn.chist@tatar.ru |
| «Ютазы районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85593) 2-98-00 | Czn.Yutazy@tatar.ru |
| «Казан шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм «Казан шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Совет районы филиалы | директор | (843) 562-48-33 (843) 273-85-03 | Czn.g_Kazan@tatar.ru CZN.Sovetskiy@tatar.ru |
| «Авиатөзелеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (843) 537-86-00 | Czn.Avia@tatar.ru |
| «Вахитов районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (843) 277-40-09 | Czn.Vah@tatar.ru |
| «Киров районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (843) 554-77-36 | czn.kirovskiy@tatar.ru |
| «Мәскәү районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (843) 564-58-72 | czn.moskovski@tatar.ru |
| «Яңа Савин районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (843) 560-88-98 | Czn.Novosavin@tatar.ru |

| | | | |
|---|---|---|---|
| «Идел буе районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (843) 224-86-83 | CZN.Privol@tatar.ru |

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 557-20-01 | mtsz@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 557-20-03 | Klara.Tazetdinova@tatar.ru |
| Эш белән тәэмин итүдә актив сәясәт чараларын гамәлгә ашыру бүлеге башлыгы | 557-20-73 | Elena.Kibardina@tatar.ru». |